СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЮГАРЫ ОСЛАН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ | КАРАР

26.09.2017 | с. Верхний Услон | № 31-140

Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22 ст., 56 ст. карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 п. 1 пункты, Югары Ослан авыл җирлеге Уставының 11 ст. карары нигезендә, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» Югары Ослан авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2017 елның 18 сентябрендәге 13-13 номерлы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2017 елның 19 ноябренә Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

«2018 елда авыл җирлегенең җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр кешесеннән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә алынган акчаларны юллау белән килешерсезме:

- Югары Ослан авыл җирлеге территориясендә урнашкан зиратларны төзекләндерү

ӘЙЕ | ЮК".

3. «Волжская новь» район газетасында әлеге карарны бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Югары Ослан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Совет Рәисе урынбасары,
Югары Ослан муниципаль районы
Югары Ослан авыл җирлеге Башлыгы урынбасары В.Ю.Раков